# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Наратлы-Кичү авыл җирлеге Исәнгол торак пунктында
гражданнар җыенының нәтиҗәләре турында

**24 ноябрь 2022ел** **№ 6**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 24 ноябрендә гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде:"Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Наратлы- Кичү авыл җирлеге Исәнгол торак пункты территориясендә үзара салымны 2023 елда һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә кертергә ризамы", көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзалары, 1и 2 группа инвалидлардан, күп балалы гаиләләрдән тыш һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлдерергә:

1) Исәнгол торак пунктында балалар мәйданчыгын төзекләндерү (балалар уен комплексларын сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

2) Исәнгол торак пунктында юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, килешү буенча түләү)

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 56 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 34 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 34 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Минзәлә муниципаль районының Наратлы-Кичү авыл җирлеге Исәнгол торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес.

2. Сорау буенча карар кабул ителде дип таныргa:"Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Наратлы- Кичү авыл җирлеге Исәнгол торак пункты территориясендә үзара салымны 2023 елда һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә кертергә ризамы", көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзалары, 1и 2 группа инвалидлардан, күп балалы гаиләләрдән тыш һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлдерергә:

1) Исәнгол торак пунктында балалар мәйданчыгын төзекләндерү (балалар уен комплексларын сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

2) Исәнгол торак пунктында юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, килешү буенча түләү) - кабул ителгән.

3. Мәгълүмат стендларында Наратлы-Кичү авыл җирлеген урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында http://menzelinsk/.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Наратлы Кичү авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Наратлы-Кичү авыл җирлеге башлыгы ____________________ Вәлиев И.М.
(имза)